РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

25.08.2022 — 793-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсештәге нәтиҗәле «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы Указлары нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсештәге нәтиҗәле «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламентын расларга.

Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Җитәкче — М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
2022 елның 25 августындагы
793-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсештәге нәтиҗәле «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы.

Әлеге Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсештәге нәтиҗәле «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» ярдәмче күрсәткечен хисап чорына исәпләү өчен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлеге регламенты Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары,«Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына «Контроль» модуленең эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнелгән һәм муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсештәге нәтиҗәле «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» ярдәмче күрсәткечен (алга

таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч) хисап чорына исәпләү өчен  җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели.

Саба муниципаль районында декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге - «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ (алга таба-мәгариф идарәсе).

1.2. Белешмә мәгълүматы.

Әлеге регламентның максатлары өчен муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән  үсештәге нәтиҗәле «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча («Мәгариф» тармагы буенча) укыган гражданнар саны» ярдәмче күрсәткечен (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч) хисап чорына исәпләү өчен  җыю һәм мониторинглауметодикасында билгеләнгән терминнар кулланыла, алар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән.

## 2.  Исәп-хисап стандарты, җыю тәртибе, һәм белешмәләр бирү

2.1. Декомпозияләнгән ярдәмче күрсәткечне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча)

2.2. Белешмәләр өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәт күрсәтүче мәгариф оешмасы тарафыннан «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» Дәүләт Мәгълүмат Системасына, «Квалификация күтәрү»  модуленә кертелә edu.tatar.ru.

2.3. Мәгариф бүлеге җаваплы хезмәткәре түбәндәге күрсәткечләр буенча хисап чорында белешмәләр җыя:

«Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасыннан «edu.tatar.ru «Квалификация арттыру» модуле - «Хисаплар» бүлегеннән йөкләмә нигезендә.

2.4. Саба муниципаль район буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән бирелә.

## 3. Мәгълүматларның составы, срогы һәм бирү формасы

«Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча) буенча мәгълүматлар бирү рәвеше

| № т/б | Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме («Мәгариф» тармагы буенча) | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү вакыты квартал саен хисап аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр | Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |